**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ЛЕШЕВ-
ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЛӘШӘҮ ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

01.11.2024ел №10

Сарман муниципаль районының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Ләшәү Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 20 маендагы 6 номерлы Ләшәү Тамак авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Ләшәү Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Ләшәү Тамак авыл җирлеге советы карар итте:

1.Сарман муниципаль районының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Ләшәү Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәне раслау турында» Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл җирлеге Советы 6 номерлы 20 май 2020 елгы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяның 9.2 пунктының 6 абзацында «түләнергә тиешле сумманы исәпләгән көннән дә соңга калмыйча» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 7 абзац өстәргә:

«бюджетка түләүләр буенча дебитор бурычларын, пенялар һәм штрафлар буенча Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән гомуми таләпләр нигезендә эшләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру регламентын билгели;»;

2) 9 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«туристлык салымы - 100 процент норматив буенча.»;

2. Әлеге карарның 1 пунктның 2 пунктчасы 01.01.2025 елдан үз көченә керә..

3. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда әлеге карарны игълан итәргә (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Ләшәү Тамак авыл җирлеге
Совет рәисе И.З.Хабибуллин